ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е КАРАР

2024 елның «26» июле № 1089

"Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 28 маендагы 886 номерлыкарары белән расланган Лениногорск муниципаль районы үзәгеннән – Лениногорск шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Лениногорск муниципаль районы авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын илтеп җиткерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының район үзәкләреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасының ерак һәм аз халыклы авыл торак пунктларына беренчел кирәк-ярак товарларын илтеп җиткерүгә бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы", "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2024 елның 28 маендагы 886 номерлыкарары белән расланган Лениногорск муниципаль районы үзәгеннән – Лениногорск шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Лениногорск муниципаль районы авыл торак пунктларына беренче кирәк-ярак товарларын илтеп җиткерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.2 түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

"Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм кулланучылар кооперациясен оештыру арасында беренче кирәкле

товарларны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск муниципаль районыннан - Лениногорск шәһәренән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына илтеп җиткерү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү булу.»;

2.1.1 пунктта «Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында» сүзләреннән соң «субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 числосына»сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктта «индивидуаль эшкуарларны, физик затларны, » сүзләрен төшереп калдырырга; 2.21 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «бюджет йөкләмәләре лимиты булмау».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo. tatarstan. ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы А.Ю. Корноухов

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72